ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**13.01.2016**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 41**

2016 елга Зеленодольск муниципаль районының сәнгать- эстетик юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 14 декабрендәге «Татарстан Республикасы сәнгать-эстетик юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» 854 номерлы карары нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты Уставы, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2016 елга расларга:
Зеленодольск муниципаль районының сәнгать-эстетик юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә кушымта итеп бирелә торган норматив чыгымнар;
сәнгать-эстетик юнәлешле балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга карата 0,5 күләмендә төзәтмәләр коэффициенты.
2. «Зеленодольск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МУ әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2016 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарала.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны мәгариф идарәсе җитәкчесе урынбасары - мәгариф идарәсе башлыгы Р.В. Афанасьевага йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А. В. Старостин

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты 2016 елның 13 гыйнварындагы 41 номерлы карары белән расланган

**Зеленодольск муниципаль районының сәнгать-эстетик юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә**

**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль урнашу | Норматив чыгымнар (1 укучыга бер елга, сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өч еллык уку вакыты | дүрт еллык уку вакыты | биш еллык уку вакыты | җиде еллык уку вакыты | Башлангыч һөнәри юнәлеш бирү |
| Музыкаль сәнгать | шәһәр җирлеге | | | 36 445 | 40 176 | 58 473 |
| Музыкаль сәнгать | авыл җирлеге | | | 40 815 | 44 972 | 65 325 |
| Сынлы сәнгать | шәһәр җирлеге | | 21 530 | | 17 753 | 45 566 |
| Сынлы сәнгать | авыл җирлеге | | 23 957 | | 19 788 | 50 778 |
| Хореография сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 41 080 | 33 340 | 131 757 |
| Хореография сәнгате | авыл җирлеге | | | 46 098 | 37 414 | 147 805 |
| Гомуми эстетик сәнгать | шәһәр җирлеге | | | 17 312 | | |
| Гомуми эстетик сәнгать | авыл җирлеге | | | 19 394 | | |
| Фольклор сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 37 283 | 34 713 | 61 871 |
| Фольклор сәнгате | авыл җирлеге | | | 41 869 | 38 994 | 69 409 |
| Эстрада-джаз сәнгате | шәһәр җирлеге | 60 705 | | 53 996 | | 95 596 |
| Эстрада-джаз сәнгате | авыл җирлеге | 68 000 | | 60 518 | | 107 040 |
| Театр сәнгате | шәһәр җирлеге | 31 677 | | 27 623 | 26 752 | 45 124 |
| Театр сәнгате | авыл җирлеге | 35 414 | | 30 898 | 29 926 | 50 270 |